

Арюковлар гаиләсе - Сажидә Ши-һаповна һәм Каюм Исхакович язмышы турында сойлисем килә. Алар Рузаевкада яшиләр. Каюм Исхак улы тумышы белән Латышовкадан. Бvген тагын бер мәртәбә безгә тормыш бvләк иткәннәрне искә аласы килә. Без жинvче халыкнын батырлыгы алдында баш иябез. Ленинградлылар алдында баш иябез. Хикәямнен топ героинясы - Сажидә Шихаповна Арюкова (Чибиляева - кыз фамилиясе) кvз яшьләре белән блокададагы Ленинградтагы vз гаиләсенен ачы язмышы турында сойләде. Бу турыда ул әнисенен истәлекләреннән генә хәтерли.
Сажидә Шиһап кызы 1941 елнын 13 маенда Рузаевка авылында туа. 1922 елда Чибиляевлар гаиләсе Ленинградка кvчеп килә.

Барысы да яхшы булган. Олы апасы Мәрьям сигез класс тәмамлаган. Һәм бер мизгелдә барысын да сугыш сызып ташлый. Чибиляевларнын да зур гаиләсен кайгы-хәсрәтләр урап узмый. Гаиләдә 5 бала: Сажидә гаиләдә ин кечесе. Әтисе белән әнисе тәvлекләр буе эштә югала башлыйлар. Сажидәнен апасы Мәрьям балаларны vзе генә карый. Ә дошман Ленинградка якынайганнан-якыная бара, аннары камалыш божрасы ябыла. Блокаданын авыр коннәре һәм тоннәре сузыла.
Гаилә альбомы архивыннан: «Мәрь ям башка яшvсмерләр белән бергә кvп катлы йорт тvбәсендә дежур тора: тагын очалар, тагын коточкыч улау белән фугаслы, яндыргыч бомбалар тошә. Менә якында гына зажигалка тошә, саны буенча ничәнче? Кызган ут чәчрәтә торган ун килограммлы болванканы эләктереп аласын да комга ташлыйсын. Анын артыннан икенчесе, оченчесе... Кизv тору очен агач кабыгы һәм пычкы белән катнаштырылган ипи паегы алган. Мәрьям, паекны куенына яшереп, изге әйбер кебек кvтәреп ойгә кайтып барысына да бvлгәннәр. Аннары, хәлсезлектән чайкала-чайкала, Нева елгасына су алып кайта иде. Ул инде блокаданын беренче коннәрендәге кебек

еламый. Бомба шартлап жиргә ыргытканда да анын кvз яшьләре юк иде. Чиләген кvтәрә дә янадан елгага таба бара: ойдә бит әнисе һәм энеләре, сенелләре. Алар шулкадәр хәлсезләнгәннәр ки, хәтта ятып кына торалар. Икмәк бирv нормасын тәvлегенә 200 грамм, 150, 125 граммга киметкәннәр... башка берни дә юк. Йорт идарәсенә эшкә кергәч, Мәрьямга икмәк нормасын 25 граммга арттырганнар. Торле чvпрәккә торенеп, ул vлгәннәрне теркәv очен фатирларга йоргән. Аннары заводка тозvче булып эшкә урнашкан. Ана тагы 25 грамм икмәк остәгәннәр.
1942 елнын язы килеп житә. Бер конне әтисе, Шихап Ганиевич, эштән сон гына кайтып керә. Ул хәрби заводта эшләгән. Ипи кисәгеннән баш тартып, авыр гына итеп кроватька ауган: әтиләре иртән тормаган. 1942 елнын 9 апрелендә Серафимовка зиратына жирләнә. Әнисе Сара Йосыф кызы кечкенә балалары белән ялгызы кала.
Ленинград урамнары vлеләр прспектына әверелә, икмәк паегы бирелә торган икмәк кибетләрендә бик зур чиратлар. Шундый куркыныч кvренеш, искә тошерvе кыен. Ленинградлылар нык һәм лаеклы чыдадылар һәм жинделәр. Блокаданын беренче озелvеннән сон Чибиляевлар гаиләсен, кvп балалы буларак, хатын-кызлар, картлар, балалар һәм авырулар белән баржалар кәрваны Ладога буйлап эвакуацияләнә. Ике дистә миль ара vтvгә, Гитлер козгыннары оча башлый. Фашистлар кемнен баржада йозгәнен бик яхшы беләләр, әмма туктамыйлар. Бомбалар һәм пулемет чиратлары, утлы-кургашын янгырын судноларга һәм кешеләргә яудыралар. Баржалар яналар, икегә ярылалар һәм баталар. Аларнын берсе бик якын иде һәм барысы да анын ягулык бакларын бомба шартлавы белән актарып ташлаганын кvрделәр... Бәхеткә каршы, баржа исән калды. Бик озак газапланып йоргәннән сон, кече Ватаныбыз Рузаевкага кайтып життек».



Мәрьям Шиһаповна хезмәт фронтында Жинv эшенә vз олешен кертте. Тимер юл бvлекчәсенен яшелчә саклагычына эшкә урнаша. Таннан танга кадәр эшли. Кайчагында тәvлекләр буе эштән китми иде. Фронт икмәгенен бәясен яхшы белә иде. Шатаев Сирач Нясибулла улына киявгә чыга. «Блокададагы Ленинградта яшәvчегә» кvкрәк билгесе, шулай ук «1941-1945 еллардагы Боек Ватан сугышы елларындагы фидакарь хезмәте очен», «Совет сәvдәсе отличнигы», «Тимер юл транспортынын Социалистик ярышлары отличнигы», «Хезмәт ветераны»медальләре белән бvләкләнә. Ул Рузаекада 1995 елда вафат була. Ә Сажидә Шиһаповна сугыштан сон Рузаевка машина исәпләv станциясендә оператор булып эшли. «Блокададагы Ленинградта яшәvчегә» билгесе, юбилей медальләре белән бvләкләнгән. 2025 елда Сажидә Шиһап кызы Арюковага «Рузаевка районынын Мактаулы гражданины» исеме бирелә. Бvген ире Каюм Исхакович белән Рузаевкада яши. Ул да ветеран - Латышовка авылында туган Исхак Нявмятуллович Арюковнын улы. Ветеранparam Ветераныбызнын исеме Днепрогэсны фашистлар чигенер алдыннан әзерләгән шартлаудан коткарган якташларыбыз, операциядә катнашучылар арасында горур янгырый. Арюковлар ике гvзәл кыз - Лиана белән Надияне тәрбияләп vстерәләр. Алар балаларынын, онык-ларынын, туганнарынын кайгыртуы һәм игътибары белән чолгап алынган. Кызы Надия Санкт-Петербургта яши, ә Лиана - Рузаевкада.
Ленинградны дошман блокадасыннан тулысынча азат итv датасын һәм Жинv конен

Арюковлар ин шатлыклы ике бәйрәм итеп билгеләп vтәләр. Балалары, оныклары һәм оныкчыклары Серафимовка зиратында әтисе Шиһап Ганиевичнын каберен онытмыйлар. Без барыбыз да Ленинградньн фидакарь яклаучыларын истә тотарга тиеш. Һәм барлык сугыш ветераннарына рухи коч, нык лык, мәнгелек ихтирам һәм рәхмәт белдерәбез.

**Фәризә Киселева (Баторшина),**
**РМ Журналистлар берлегенен**
**«Алтын каләм» конкурсы жинvчесе**